КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 2 сентябрь г.Казань № 740

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының сәүдә, кунакчыллык индустриясе, сервис һәм хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә фәнни-белем бирү кластерын оештыру турында» 2011 ел, 21 март, 210 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 16 ноябрь, 938 нче; 2012 ел, 15 июнь, 516 нчы; 2013 ел, 21 май, 334 нче; 2014 ел, 20 май, 333 нче; 2014 ел, 18 октябрь, 770 нче; 2015 ел, 25 декабрь, 983 нче; 2016 ел, 27 декабрь, 1002 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының сәүдә, кунакчыллык индустриясе, сервис һәм хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә фәнни-белем бирү кластеры составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

икенче һәм өченче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яр Чаллы технология техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе;

«Казан технология һәм дизайн көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе;»;

җиденче абзацны төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан дәүләт мәдәният институты» югары белем бирүче федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең фәнни-белем бирү кластерын оештыру турында» 2011 ел, 30 март, 241 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 15 июнь, 516 нчы; 2014 ел, 20 май, 333 нче; 2015 ел, 25 декабрь, 983 нче; 2016 ел, 27 декабрь, 1002 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Казан дәүләт мәдәният институты» югары белем бирүче федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең фәнни-белем бирү кластеры составына, дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Казан халык сәнгать һөнәрләре техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе.».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары һөнәр белеме бирүче «Н.Э.Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе» федераль дәүләт бюджет белем учреждениесе фәнни-белем бирү кластерын оештыру турында» 2011 ел, 22 апрель, 320 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 15 июнь, 516 нчы; 2013 ел, 21 май, 334 нче; 2014 ел, 20 май, 333 нче; 2014 ел, 18 октябрь, 770 нче; 2015 ел, 25 декабрь, 983 нче; 2016 ел, 27 декабрь, 1002 нче; 2018 ел, 20 февраль, 101 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Югары һөнәр белеме бирүче «Н.Э.Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе» федераль дәүләт бюджет белем учреждениесенең фәнни-белем бирү кластеры составына, өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Аксубай универсаль технологияләр техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе;».

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан дәүләт аграр университеты» югары белем бирүче федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе фәнни-белем бирү кластерын оештыру турында» 2011 ел, 28 апрель, 350 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 15 июнь, 516 нчы; 2013 ел, 21 май, 334 нче; 2014 ел, 20 май, 333 нче; 2014 ел, 18 октябрь, 770 нче; 2015 ел, 25 декабрь, 983 нче; 2016 ел, 27 декабрь, 1002 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Казан дәүләт аграр университеты» югары белем бирүче федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең фәнни-белем бирү кластеры составына, сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе.».

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» югары белем бирүче федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе фәнни-белем бирү кластерын оештыру турында» 2011 ел, 6 июль, 546 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 21 май, 334 нче; 2015 ел, 25 декабрь, 983 нче; 2016 ел, 27 декабрь, 1002 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» югары белем бирүче федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең фәнни-белем бирү кластеры составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

дүртенче һәм бишенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бөгелмә медицина училищесы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе.

«Буа медицина училищесы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе.»;

җиденче һәм сигезенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Зеленодольск медицина училищесы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе.

«Минзәлә медицина училищесы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе.»;

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Чиста медицина училищесы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе.».

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының нефть-газ комплексы өчен кадрлар әзерләү буенча фәнни-белем бирү кластерын оештыру турында» 2013 ел, 19 август, 571 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 18 октябрь, 770 нче; 2015 ел, 25 декабрь, 983 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада, 1 нче, 3 нче, 4 нче пунктларда «В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ачык акционерлар җәмгыяте» сүзләрен «В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлар җәмгыяте» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының нефть-газ комплексы өчен кадрлар әзерләү буенча фәнни-белем бирү кластеры составында:

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлар җәмгыяте (килешү буенча).»;

6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Өстәмә һөнәри белем бирүче «Кадрлар әзерләү үзәге – Татнефть» шәхси мәгариф учреждениесе (килешү буенча).»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының нефть-газ комплексы өчен кадрлар әзерләү буенча фәнни-белем бирү кластеры яраштыру советы турындагы нигезләмәдә:

2.1 нче, 4.1 нче пунктларда һәм 3.1 нче пунктның 3.1.12 нче пунктчаларында «В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ачык акционерлар җәмгыяте» сүзләрен «В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлар җәмгыяте» сүзләренә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин